Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан КОММУНИСТЫ

№ 1-2 (25-26). 2012 ел, 16 март. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы



## Гомәр Исмәгыйлевич Усмановка – 80 яшь!

1982 елның 29 октябрендә ул КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре булып эшли башлый. Аңа кадәр Чистай һәм Буа районнарын җитәкли, 16 ел буе Татарстан Министрлар Советы председателе була. Аның җитәкчелегендә республикада нефть чыгару һәм автомобиль промышленносте көчле үсеш алды. Совет партия һәм дәүләт эшлеклесе булып, ул тарихка кереп калды.

Гомәр Усманов 1932 елның 16 мартында Чистай шәһәрендә туган. 1966 елда Татарстан Министрлар Советын җитәкли башлаганда аңа нибары 34 яшь була. СССРдагы республикалар арасында иң яшь хөкүмәт башлыгы! Ул үзен талантлы оештыручы, белемле һәм энергияле җитәкче итеп танытты.

ТАССР Министрлар Советы председателе постында эшләгән елларын ул болай искә ала: «Хәзер булсын иде әле ул еллардагы торгынлык! 70нче, 80нче еллар киеренке хезмәт, халык энтузиазмының күрелмәгән күтәрелеше, чәчәк ату чоры булды. Бу елларда без нәрсәләр төзедек? Түбән Камада нефтехим комбинаты, ул бөтен СССРда иң эре, уникаль предприятие булды. Ә янәшәдә генә биш ел эчендә КамАЗ автогигантын корып куйдык».

1989 елның 20 сентябрендә аны КПСС Үзәк Комитеты секретаре итеп сайлыйлар. 1990 елдан – пенсиядә.



Г. Усманов, 1980 еллар.

# РОССИЯГӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КИРӘК!

## Россия гражданнарына мөрәҗәгать

Россия Федерациясендә Президент сайлаулары тәгәлләнде. Без, аларның ни ирекле, ни намуслы булмаячагын алдан ук бик ачык белә торып, анда катнашырга дигән карарга килгән идек. Безнең төп бурыч илне торгызуның үзебез төзегән яңа программасын, яңа курсны һәм Халык ышанычы хөкүмәте составын җәмгыятькә тәкъдим итү иде.

Сайлау алды кампаниясе тормышыбыздагы бөтен «авырткан җирләрне» бергәләп бәяләргә һәм аларны дәвалау юлларын табарга мөмкинлек бирергә тиеш иде. Кызганыч, диалог барып чыкмады. Без узган сайлауларны легитим булды дип таный алмыйбыз, аны демократияле һәм намуслы булды дип тә санамыйбыз. Хакимлек итүче командa проблемалар турында тирәнтен фикер йөртергә алынмады, программаларны ачыктан-ачык ярыштырырга җөрьәт итмәде. Хәтта информацияләр мәйданында зур өстенлекләргә ия булуына карамастан, Путин әфәнде дебатларда катнашудан читкә тайпылды, үзенең изге ниятләр белән шыплап тутырылган «программа мәкаләләре»ндәге сүзләр дәрьясы артына качты. Хакимлек итүче даирәләр кискен мәсьәләләр буенча киң дискуссияләрдән хөкүмәт тарафдарлары оештырган митингларда катнашучылар артына яшеренделәр. Халык аң томалауның коточкыч чараларына дучар ителде. Кешеләрне сайлауда оппозиция кандидаты җиңә калса, колак ишетмәгән, күз күрмәгән афәтләр килеп чыгу ихтималы булу белән куркыттылар.

Гади генә әйткәндә, Россиядә сайлау мөмкинлеген урладылар. Телләгән нәтиҗәсенә ирешү өчен власть вертикале яшерен эш итү, ялганлау һәм фактларны бозып күрсәтү, хәрәмләшү кебек мөмкинлекләрнең барысын да сугыш мәйданына чыгарды. Чиновникларга тавыш бирү йомгакларының контроль саннары алдан ук җиткереп куелды. Хокук саклаучылар тәртип бозуларга күз йомды. Алар «Алла сакласын!» стилендәге ялганялагай газеталарның чыгуын тыймады, хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итүләр, төрле сәбәпләр табылып, читкә тибәрелде, тикшерелмәде. Сайлау комиссияләренең составларында да үзгәрмәде. Үзәк сайлау комиссиясе председателе булып Владимир Чуров калды. КПРФның сайлау системасын камилләштерүгә кагылышлы Закон проектлары Дәүләт Думасы тарафыннан кабул ителмәде. Намуслы сайлаулар урынына гражданнарга веб-камералар урнаштыру кампаниясе тәкъдим иттеләр. Тавыш бирү көнендә участоклардан КПРФ күзәтүчеләрен генә түгел, ә кайбер регионнарда хәтта хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия булган сайлау комиссиясе членнарын да куып чыгару цинизмның чәчрәп торган иң югары ноктасы булды.

Бу хәлләрнең сәбәбе аңлашыла. Халыкның күпчелеге алып барыла торган социаль-экономик һәм политик курстан канәгать түгел. Власть моны белә һәм шуңа күрә халык авазы сайлау алды манипуляцияләре аша үтеп чыга алмасын өчен барысын да эшләде.

Тавыш бирүләрнең игълан ителгән нәтиҗәләре халык массаларының чынлыктагы кәефен дә, ихтыярын-теләген дә чагылдырмый. Россиядә сайлауларны фальсификацияләүнең коточкыч сис-



темасы булдырылды, сайлау комиссияләренең йөз меңләгән членнары да шунда кертелгән. Моңа әле сайлаучыларга басым ясый торган җирле һәм региональ администрацияләр хезмәткәрләрен, предприятиеләр һәм бюджет оешмалары җитәкчеләрен дә кушсак, сүзнең киң колачлы фальсификация хакында икәнлеге һәм, теләсә-теләмәсә дә, миллионлаган гражданнарның шуңа җәлеп ителүе турында баруы аңлашыла. Путинны яклап тавыш бирергә кешеләрне эштән кыскартулар белән янап, хезмәт хакларын кисеп, туганнарына каршы репрессия чаралары кулланып һәм башка юллар белән, кем әйтмешли, кулларыннан тотып мәҗбүр иттеләр. Хакимлек итүче режимның «чуровча җиңүенә» әнә шулай ирештеләр.

Шулай да соңгы сайлаулар вакытында Россия җитди үзгәрешләр кичерде. КПРФ һәм безнең союзниклар җәмгыятькә сайлау кампаниясенең үзәген тәшкил иткән, тормыш чынбарлыгының төп проблемаларына кагыла торган көн тәртибе тәкъдим иттеләр. Без табигый ресурсларны национализацияләүне, финанс системасына дәүләтнең контрольлек итүен кертүне, яңа социаль политиканы, керем налогларын алуның прогрессив юлларын яклап чыктык. Бу мәсьәләләрдә дә, башка сорауларда да гражданнар тарафыннан киң яклау таптык.

Безнең идеяләр һәм тәкъдимнәр хәзер бөтен җәмгыятьнең казанышлары булып тора. Яңа политика орлыклары чәчелде. Бу үсеш, гаделлек һәм прогресс орлыклары, һичшиксез, шытып чыгачаклар. Безнең сайлау алдыннан алып барган эшебезнең төп нәтиҗәсе әнә шул.

Сайлау кампаниясенә тулы нәтиҗәләр әле ясала гына. Әмма халыкның таләбе инде ачык: Россиягә үзгәрешләр кирәк! Гражданнарның бурычы – я җәмгыятьнең ихтыяҗларына тулысынча җавап бирергә, я дәүләт белән идарә итү штурвалын киеренке зур эшләр башкарырга әзер булганнар кулына тапшырырга властьны мәҗбүр итү. Халык активлыгын инде күрсәтте: властька басым ясау мөмкин эш һәм бу шулай кирәк тә.

Россия хезмәт ияләре, аның ветераннары һәм яшьләре үз мәнфәгатьләрен торган саен яхшырак аңлый баралар. Халыкның шушы күпчелегенә таянып, КПРФ, үз союзниклары белән берлектә, илне криминаль-мафиоз богаулардан йолып алу өчен мөмкин булганның барысын да эшләячәк. Бу эшчәнлектә без үз тарафдарларыбызның теләктәшлегенә һәм ярдәменә нык исәп тотабыз һәм 4 март көнне яңа Россия файдасына тавыш биргән һәр кешегә тирән ихтирамыбызны белдерәбез. Без шулай ук илгә чиста юл белән сайлауларны кайтарырга дигән омтылыш белән җиң сызганып эшләгән дистә меңләгән күзәтүчеләргә, сайлау комиссияләре членнарына да чиксез рәхмәтлебез.

Илдәге социаль-экономик курсны алыштыру өчен кәрәшне без бернинди тукталышсыз һәм өзеклексез дәвам итәбез. Яхшы якка үзгәрешләрне якынайту максатында, без гражданнарның референдумга булган хокукларын кайтару өчен тырышачакбыз. Без сайлауларны фальсификацияләүләр өчен җәзаны кырысландыруны яклап чыгабыз һәм сайлау комиссияләрен төзегән вакытта партияләрнең тигезлеге саклануны таләп итәбез. КПРФ үзенең таләпләре күрсәтелгән программаны власть органнарына булачак сайлауларда да, барлык дәрәҗәдәге җирле үзидарә сайлауларында да үткәрәчәк. Сул патриотик көчләр массаларны үз хокукларын һәм мәнфәгатьләрен күмәкләп яклауга күтәрәчәк.

Бүгенге Россия каршына тарихи дилемма тагын да кискенрәк төстә килеп басты: колониаль чүгү һәм үлеп бетү юлымы, әллә тыныч хезмәт, халыклар дуслыгы һәм социаль гаделлек юлымы? КПРФ өчен гражданнарның күпчелегенең позициясе ачык аңлашыла. Россия халкы илне кече һәм чәчәк ата торган итеп күрергә тели. Илдә кичектергесез тестә үзгәрешләр кирәклегенә шикләнүчеләр саны кимегәннән-кими. Халыкның күпчелеге аны зарыгып көтә, ә урлап баеган азчылык аннан курка, бу эшкә комачауларга тырыша.

Мин ышанам: тырышлыкны арттырганда, без сезнең белән тормышыбызны яхшы якка үзгәртә алабыз.

**Геннадий ЗЮГАНОВ,**
**КПРФ Үзәк Комитеты председателе.**

## Шәхесләребез: Г.И. Усманов



Г. Усманов һәм Ю. Гагарин, 1967 ел.

**– Милли-мәгариф өлкәсенә нинди килечәк «юрыйсыз»? Әллә сезнең күзаллаулар сәяси-икътисади өлкәгә генә карыймы?**

– Юк. Мин эшләгәндә бер генә иҗат берлеге дә бинасыз калмады. Язучылар берлеге дә, рәссамнар да, архитекторлар да офислы булдылар. Минемчә, тел бар – милләт бар, тел юк – милләт бетә. Татар мәктәпләре темасы мине дә бик борчый. Язучыларның бер съездында чыгыш ясаганда үзләрен бик ачуланган идем. «Татар мәктәпләре аз», – дип зарлангач, язучылардан сорадым: «Кулларыгызны күтәрегез әле, кайсыгызның баласы татар мәктәбендә укый?» – дим. Беркем кул күтәрми. «Мин барып урнаштырыйммы балаларыгызны?» – дим. Кайберәүләр көлә башлагач: «Көлмәгез, дим, елагыз»…

**– Хәзер Мәскәү бөтенләй кысып бетермәсме икән? Алгарак карап нәрсә күрене анда?**

– Барысы да урындагы җитәкчеләрдән тора…

**– Хәзер нинәр эшлисез? Вакытыгызны ничек уздырасыз?**

– Менә бит, – Гомәр Исмәгыйлевич зур кабинетны өч яклап әйләндереп алган, шыплап тутырылган китап киштәләренә ымлый.

**Рузилә МӨХӘММӘТОВА.**

## Котлыйбыз!

Татарстан Республикасының элеккеге җитәкчесе, 1953 елдан Коммунистлар партиясе члены Гомәр Исмәгыйлевич Усманов, 80 яше тулу уңаеннан, КПРФ Үзәк Комитетының «М.В. Ломоносовка 300 яшь» истәлек медале белән бүләкләнде.

# ХӘБӘРЛӘР

## Без җиңдек!

**Казанда льготаларга ия кешеләр җәмәгать транспортында кабат берниндичикләүләрсез файдаланалар.**

Казанда җәмәгать транспортында льготалы йөрү санын чикләүләр туктатылды. Исегезгә төшерәбез, 13 гыйнвар көнне Татарстан Президенты Республика Министрлар Кабинетының ташламаларга ия булган кешеләрнең йөрүен чикләү турындагы карарын юкка чыгару турында йөкләмә биргән иде.

Бу карар тик торганнан гына кабул ителмәде. Аны протестлар, кешеләрнең күмәк чыгышлары басымы астында кабул итәргә мәҗбүр булдылар. 9 гыйнварда йөзләгән шәһәрдәшләребез Казанның үзәгенә КПРФның республика комитеты оештырган митингка җыелдылар. Анда шәһәрнең җәмәгать оешмалары да катнашты. Ачулары кабарган протест белдерүчеләрнең максаты һәм теләге дистәләгән чыгышларда яңгыраш тапты, алар нигезендә «Безнең льготаларны кайтарыгыз!» дигән таләп ята иде.

Бүгенге көндә тиешле җиһазларның (валидаторлар) программалары кабат үзгәртелде, хәзер социаль проездной билеты булган казанлыларга җәмәгать транспортында берниндичикләүләрсез йөрү мөмкинлеге кайтарылды.

**Рамил ГАЙФУЛЛОВ,**
**КПРФ Татарстан рескомының яшьләр эше буенча секретаре.**

## Рәхмәт хаты

**КПРФ рескомы беренче секретаре, Татарстан Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе Х.Г. Миргалимовка.**

***Хөрмәтле Хафиз Гаязович!***

XX гасырның атаклы кешесе Владимир Ильич Ленин турында истәлекне киләчәк буыннарга саклап калдыру мөмкинлеген бирүче В.И. Ленинның Музей-йортына реконструкция һәм реставрация ясау кебек мөһим мәсьәләне хәл итүдә катнашуыгыз өчен Сезгә чын күңелдән рәхмәт белдерәбез. Бу Сезнең эшлекле катнашыгыздан, бертуктаусыз кайгыртуыгыздан һәм КПРФның региональ бүлеге яклавыннан башка була алмас иде.

Без Сезнең энтузиазмны югары бәялибез, эшкә җаваплы каравыгыз һәм югары профессионализмыгыз безнең өчен үрнәк булып тора.

Сезгә һәм Татарстан коммунистларына эшләрегездә алга таба да уңышлар, үз көчегезгә нык ышануыгызны, сафларыгызның бердәм булуын, ныклы сәламәтлек һәм иминлек телибез!

Киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәттәшлеккә өмет һәм ихтирам белән,

**Т.И. БАСОВА,**
**В.И. Ленинның Музей-йорты директоры һәм музей хезмәткәрләре.**



## Халыкны полициядән яклыйк!

**Полицейскийлар башбаштаклыгына чик куелсын!**
**Татарстандагы вакыйгаларга карата җәмәгатьчелек резонансы**

Коммунист-депутатлар В.И. Кашин, Н.В. Арефьев, И.И. Никитчук, А.Ю. Русских, В.Н. Паутов Дәүләт Думасының 2012 елның 14 мартында узган пленар утырышында полицейскийлар башбаштаклыгын туктатуны таләп иттеләр.

Шундый рәсми документның барлыкка килүенә сәбәп – Татарстан Республикасында гражданин С. Назаровны полиция бүлегендә мыскыллау-мәсхәрәләүнең үлем белән тәгәлләнүе булды.


Беркетмәгә теркәлгән йөкләмәдә болай диелә:

Дәүләт Думасы куркынычсызлык комитетыннан Россия Федерациясе Прокуратурасына һәм Тикшерү комитетына тоткарланган гражданнарның полиция хезмәткәрләре тарафыннан, чынлыкта системалы төс алган, ахыры фаҗига белән тәгәлләнгән, мыскыллану-мәсхәрә ителү очраклары һәм, полиция тарафыннан Россия законнары һәм гражданнарның хокуклары бозылган очракларда, полициянең гади хезмәткәрләренә генә түгел, ә Россия Федерациясенең һәм төбәкләрдәге эчке эшләр министрларын да кертеп, югары звено җитәкчеләренә карата нинди чаралар күрелүе турында мәгълүмат әзерләргә кушуыгызны сорыйбыз. Шундый коточкыч хәлнең соңгысы Татарстан Республикасында гражданин С. Назаровны мыскыллау-мәсхәрәләүнең үлемгә китереп җиткерүе булды.

Алынган мәгълүматларны депутатлар игътибарына җиткерергә.

# БЕЗ ГАДЕЛ САЙЛАУЛАР ЯКЛЫ

## Г.А. Зюгановның 2012 елның 23 февралендә Мәскәүдә узган митингта ясаган чыгышы



**23 февраль көнне Мәскәүнең үзәгендә коммунистларның һәм сул-патриотик көчләр тарафдарларының күпмеңләгән кешеләр катнашында Совет Армиясе һәм Хәрби-Диңгез Флотының 94 еллыгына багышланган митингысы булып узды. Акциядә катнашучылар каршында КПРФ Үзәк Комитеты Председателе, Россия Президентлыгына кандидат Геннадий Андреевич Зюганов чыгыш ясады.**

Кадерле дуслар! Иптәшләрем минем! 1000 еллык тарихы булган безнең держава – халкыбыз арасында, ышанычыбызны, дәреслекне, гаделлекне, бар яхшылыкны һәм намусыбызны яклап, күкрәге белән үз Ватанын саклый алган кешеләр булганга күрә бөек держава ул.

Дмитрий Донскойның Коломнаның текә ярында, илбасарларга каршы тору өчен Куликово кырына бөтен Русьны дәшеп, басып торуы очраклы гына булмаган. Без ул чакта җиңеп чыктык, ә аннары дөньядагы иң зур дәүләтләрнең берсен төзедек. Бөек Петр Полтава янында бөтен Европаны үзенә буйсындырган шведларны тар-мар итте. Бу елда илебез Бородино сугышының 200 еллыгын билгеләп үтәчәк. 1812 елда Кутузов француз армиясен тар-мар итте, без аны Парижга кадәр кудык.

Николай Икенче империяне юкка чыгарып, ә буржуаз-алпавытлар классы ил белән тиешенчә идарә итә алмаган чорда Ленин үз байрагы астына өч ел эчендә 5 миллионлы армия туплады һәм бөтен Антантаны – безнең киңлекләргә бәреп кергән 14 дәүләтнең гаскәрләрен шулай ук тар-мар итте. Яшь Совет Республикасы һәм яшь Кызыл Армия Гражданнар сугышы ялкыннарында туды һәм чыныгу алды.

Безнең илебез санаулы еллар эчендә меңнәрләгән предприятиеләр төзеде, бөек фәнни мәктәп булдырды һәм дөньяда тиңе булмаган иң яхшы мәгариф системасын корды. Фаҗигале һәм дәһшәтле 41нче елны без дөньядагы иң яхшы корал белән каршы алдык. Гитлерда безнеке кебек Т-34 танклары да, «Катюша» БМ-13 кебек артиллерия системасы да, Ил-2 кебек штурмовиклар да юк иде. Ә бит Германия, портларны, аэродромнарны, промышленность предприятиеләрен, ресурсларны һәм фәнни үзәкләрне үз кул астына буйсындырып, бөтен мактаулы Европаны санаулы айлар эчендә тулысынча яулап алган иде инде. Шулай булуга карамастан, Кызыл Армия – көчлерәк, ә Сталин һәм Жуков җитәкчелегендәге совет командованиесе зирәгрәк һәм талантлырак булып чыкты.

Безнең держава санаулы еллар эчендә сугышның тетрәндергеч нәтиҗәләреннән арына алды. Янарып, күтәрелеп кенә калмадык, ә 10 ел дигәндә, Америкаңыкына тиң ракета-атом-төш калканын булдырдык. Җиңү һәм Октябрь байрагы астында без иксез-чиксез киңлекләрне үзләштердек, социаль тәэминатның иң яхшы системасын оештырдык, галәм киңлекләренә чыктык.

Әмма югарыдагылар безгә хыянәт итте, мең ел дәвамында держабабыз туплаган байлыкны сатып бетерде. Искиткеч зур байлыкны олигархлар арасында бүлештеләр, бүген исә шушы камарильяга хезмәт күрсәтүне, «океан арты обкомы»н түендерып ятуны дәвам итәләр.

Исегезгә төшерәсем килә, безне бер генә сугышчан походта да җиңә алмадылар. 1000 еллык тарихның 700 елын без бәйсезлек өчен сугышта үткәрдек. Безне ялган микрофоннар да, оятсыз лозунглар да һәм хаин җитәкчеләр дә ни алдый, ни юкка чыгара алмады. Мин хәзер, 20 ел вакыт узгач, зур территорияләрне югалтып, тугандаш республикаларны, бигрәк тә Украинаны, Белоруссияне чик сызыгы артында калдыргач, инде ниһаять информацион-психологик факторлар хәлиткеч роль уйнаган яңа сугышта җиңелүне тануларын телим. Алдауга һәм күз буяуга корылган сайлауларда ялган җитәкчеләр билгеләнде, алар промышленностьны, армияне, авыл хуҗалыгын, барлык социаль казанышларны юкка чыгардылар.

20 ел вакыт узгач, бу фаҗигане аңлап, гражданнар кинәт уянгандай булды. Декабрьдә узган Дума сайлауларыннан соң зиһеннәр бигрәк тә ачылып киткәндәй булды. Кешеләр властьтагы партиянең намуслы сайлаулар уздыра алмаганлыгын күрделәр. Ул әлеккечә үк тавышларны «урлый» һәм протоколларны кучереп яза икән ләбаса.

Без башка политик көчләр белән үзара сөйләштек һәм бу яңа сугышта – нервылар сугышында, характерлар бәрелешендә, намуслы сайлаулар өчен бара торган көрәштә җиңеп чыгар өчен барысын да эшләргә дип килештек. Бүген бу көрәш һәр йортта, һәр телевизор экраны каршында һәм һәр предприятиедә бара. Аны тавыш җыю урнасына бюллетень сала торган һәр гражданин, яисә сайлау комиссиясендә эшли торган һәрбер кеше алып бара. Сезгә турысын әйтергә телим: бу Мәскәү өчен, Сталинград өчен, яисә Орлов-Курск дугасында барган сугышлардан бер дә ким түгел. Әмма без бүген бердә – башкала үзәгендә җыелып, бу сугышта җиңеп чыгарга сүз бирергә тиеш, чөнки без бүгенге көндә сатылган һәм хыянәткә дучар ителгән бөек җиңүләребезгә таянабыз.

Мин һәрберегездән дусларыгызга, якыннарыгызга, күршеләрегезгә, хезмәттәшләрегезгә мөрәҗәгать итүегезне үтенеп сорыйм. Бүген иң мөһим нәрсә – информацион мафиягә һәм угрылыкка корылган олигарх системасына каршы көрәш фронтына барыбызның да бердәм булып чыгуы кирәк. Аны бары тик төгәл оешканлык һәм куәтле протест ярдәмендә генә җиңеп була. Сайлауларга никадәр күбрәк кеше килсә, тавышларны шулкадәр азрак урлый алачаклар. Ә намуслы сайлауларда Путин әфәнде беренче турда берниндишартларда да җиңә алмаячак.

Һәр сайлау комиссиясенең җитәкчесенә турыдан-туры шуны да әйтеп кую кирәк: әгәр тавышларны урлыйсыз, өстәп яки бозып язасыз икән, без сезне җинаять срогы беркайчан да гамәлдән чыкмый торган җинаятьчеләр исемлегенә кертәчәкбез һәм үзегезне дәүләт властен яулап алучылар дип санаячакбыз.

Бүген «Бердәм Россия» башка мәйданнарда һәм стадионнарда Путинны күмәкләп яклавын күрсәтәчәк. Әмма бу күмәклек нигездә сатып алынган күрсәткеч кенә. Мин кичә хезмәт ияләре белән очраштым, алар: «Геннадий Андреевич, безне, акча түләп, автобусларда алып килделәр. Безнең егерме ел инде Мәскәүдә булганыбыз юк иде, чөнки билет бәяләре бик кыйммәт. Митингка исә эштән куабыз дип янап китерделәр. Ләкин без барыбер сезне яклап, халык власте өчен, намуслы сайлаулар һәм илебезнең лаеклы киләчәге өчен тавыш бирәчәкбез!» – диделәр.

Без «сугыш балалары», ә алар илдә 14 миллион кеше, тыл хезмәтчәннәренеке кебек үк ташламаларга ия булсын өчен барысын да эшләячәкбез. Без һәрбер яшь кешегә түләүсез белем алуны, шул исәпкә югары белем алу да керә, һәм беренче эш урыны булдыруны гарантияләүгә ирешәчәкбез.

Без бюджетның 10-15 процентын авылны торгызуга тотачакбыз. Шуннан башка ил яши дә, үсә дә алмый.

Без шулай ук Россия, Украина, Белоруссия һәм Казахстан бердәмлеген торгызу өчен барысын да эшләячәкбез, чөнки бу безгә бөтен дөнья базарында көндәшлеккә сәләтле булу мөмкинлеген бирә.

Мин алда торган бу бурычларны үтәп чыгачагыбызга ышанам. Безнең команда көчле. Безнең кадрлар тәҗрибәле. Безнең арта – җиңүләрнең мең еллык тәҗрибәсе. Безнең партия артында – социализмның, гаделлекнең һәм халыклар дуслыгының йөз еллык тарихы. Яшәсен безнең армия, яшәсен Совет власте, яшәсен җиңүче халык, яшәсен яңа җиңүләр!

# «Патша чын түгел икән бит...»

## 2012 елның 13 мартында Дәүләт Думасының пленар утырышында КПРФ фракциясе исеменнән В.Ф. Рашкин чыгышы

Безнең лидер Геннадий Зюганов сайлауларга кадәр дә намус белән эшләде, сайлаулардан соң да үзенең сайлаучылары каршында намуслы булып калды. Гражданнарның күпчелеге кебек үк, ул да узган сайлауларны иректә булмады, намуссыз һәм гаделсез үтте дип саный. Компартия аны бер генә төрле бәяли – легитим түгел.

Без сайлау чорында дәүләт структураларының нейтраль оештыручы гына түгел, ә кандидат Путин яклы азартлы һәм принципсыз уенчы икәнлеген искәртеп, сайлау комиссияләренең, бәйсез матбугат чараларының, администрацияләрнең ишекләрен күп кактык. Без тавыш бирү көнендә дә шушы хакта сөрән салып кычкырдык. Без моны тәнлә – тавышларны санаганда да теркәдек. Җәмәгатьчелек безне ишетте, митинглар белән җавап бирде. Ә Үзәк сайлау комиссиясе «чуродейлары» һәм хокук саклау органнары бары тик «Путин һәрчак хаклы» принцибы буенча гына эш иттеләр.



**В.Ф. Рашкин, Госдума депутаты, КПРФ Үзәк Комитеты секретаре.**

Дәүләт тарафыннан, яисә Путинның «Озеро кооперативы» буенча дуслары тарафыннан контрольдә тотылган федераль телеканаллар сайлау алды чорында бары тик бер генә кандидатка мәдхия җырладылар. Бәйсез исәпләүләргә караганда, кампания башланганнан алып, Путинга телеэфирның 70 проценты – 66 сәгать информацион-политик эфир плюс агитпериод чорында тагын 8 сәгать вакыт бирелде. Ә Зюгановның ике айда 6 сәгать 50 минутлык информацион-политик хәбәрләрдә исеме телгә алынды да шул агитпериодтагы 8 сәгать вакыты булды.

Илне информацион көчләүләрне Хөкүмәтнең эшен тирәнтен яктырту дип акладылар. Тарихта ихтимал моңа кадәр күрелмәгәнчә киң масштаблы һәм иң зәвыксыз «Путин бүген тагын кемне коткарды?» дигән реалити-шоуны күрдек, иң аянычы – моның өчен алар үз кесәләреннән чыгарып түләделәр.

Манеж, Болотная, Пушкин мәйданнарында, Сахаров проспектында узган «Гадел сайлаулар өчен» дип аталган күпмеңләгән протест акцияләренә карата сәламәт карашлы реакция күрсәтәсе урында, аларга җавап йөзеннән власть үз «путинг»-митингларын оештырды, аларга, күмәк мәгълүмат чараларының хәбәр итүенчә, кешеләрне акча түләп һәм эштән чыгару белән куркытып җыйдылар. Фальсификацияле сайлауларны яклап, фальсификацияле митинглар оештыру бары тик Путин Россиясендә генә мөмкин булган эштер ул.

Хокук саклау органнары тәртип бозуларга күрәләтә торып күз йомды. Алар «Алла сакласын!» стилендәге ялганялагай газеталарның чыгуын тыймады. Сайлау комиссияләре дә ләм-мим сүзсез булды. Сайлау комиссияләренең составы да чылыкта үзгәрмәде. Үзәк сайлау комиссиясе председателе булып шул ук Чуров калды, аның исеме хәзер тискәре мәгънәдә генә яңгырый.

Ә бит властьның сайлауларны, бүгенге көндә сайлаучылар аның легитимлыгында шикләнмәслек итеп, чиста һәм намуслы итеп үткәрү мөмкинлеге бар иде. Моның өчен КПРФның сайлау турындагы законнарны төзәтүремонтлау инициативасын хупларга, сайлау комиссияләренә төрле партияләрнең вәкилләрен бердәй дәрәҗәдә күреп, тигез тәкъдим итәргә генә кирәк иде. Җитмәсә, моны эшләү өчен бер тиен дә өстәмә чыгым сарыф итәсе дә түгел иде.

Сайлау участокларында веб-камералар кую кебек кыйммәткә төшкән пиар-кампания операциясе җәмәгатьчелек фикерен алдый алмады. Бик күпләр төп фальсификацияләүләрнең тавыш биргән көнне веб-камералар күзәтүе астында алып барылмаганлыгын бик яхшы аңлыйлар. Административ ресурслар, тавыш бирү көнендә генә түгел, аннан да биграк, агитацияләү чорының буеннан-буена сайлаучыларның ихтыярын һәм аңын богаулап торды.

Хәер, веб-камералар астында да төрлесе булды: өстәмә бюллетеньнәр дә салдылар, күзәтүчеләрне һәм сайлау комиссиясе членнарын чыгарып та җибәрделәр, бюллетень санаганда тәртип бозулар да күзәтелде... Участок сайлау комиссияләре беркетмәләрен традицион төстә территориаль сайлау комиссияләрендә күчереп яздылар. Әмма бу юлы да административ ресурсларның төп ставкасы сайлаучылар исемлегендәге манипуляцияләргә, «карусельләргә», өйдә һәм өстәмә сайлау участокларында тавыш бирүләргә куелды.

Россиядә сайлауларны фальсификацияләүләрнең коточкыч зур системасы булдырылды – чып-чын спрут. Аңа йөз меңләгән бюджетниклар һәм муниципаль предприятиеләр хезмәткәрләре – сайлау комиссияләре членнары, җирле һәм региональ администрацияләр хезмәткәрләре кертелде. Угрылар оясы диярсең, һәммәсе дә тотылды.

Игътибарга лаек берничә мисал китерәм. Үлеп бара торган илдә узган Президент сайлауларыннан соң сайлаучылар саны 2,6 миллионга арткан.Ә тавыш бирү көнендә иртәдән кичкә кадәр вакыт эчендә илдәге тавыш бирүчеләр саны, ниндидер могҗиза белән, 1 миллион 200 мең сайлаучыга арткан! Чыннан да, могҗиза түгелмени бу? Бала яралганнан алып туганга кадәр тугыз ай вакыт үтә, ә монда – бер көн эчендә!!! Питерда андыйлар саны 378 мең булган, бу исә исемлектәгеләрнең – 10, ә Путинны яклап тавыш бирүчеләрнең 27 процентган артыграгы дигән сүз. Мәскәүдә алар – 250 мең, Путинга бирелгән тавышларның 12 процентын тәшкил итә.

Түбән Новгородта, гомумән, 16 фантом участок булуы ачыкланды. Тавыш бирергә берничә көн калганда, предприятиеләрдә, базарда һәм башка шундый үзенчәлекле урыннарда өстәмә сайлау участоклары пәйда була башлады. Андыйларга безнең күзәтүчеләрнең юлы ябык булды, ә бит ял көне, ни хикмәт, эш көне дип игълан ителгән! Адәм көлкесенә тиң күренешләр дә бар. Түбән Новгородта 2512нче номерлы сайлау участогы борынгы Бугровское зиратында оештырыла, анда сайлаучыларның 88 проценттан артыгы Путинны яклап тавыш бирә! Миндә бер сорау туа: зиратта Путинга тавыш бирген 1637 җан – кемнәр алар? Чалгы тотып чыккан мәрхүмнәрме әллә?

Сүз уңаеннан бер үзенчәлекле факт – бу юлы Мәскәү һәм Россиянең күп кенә регионнары Путинга тоташ ышаныч белдерүдән баш тартканнар. Чечня, Ингушетия, Дагыстан, Карачай-Черкесия исә чиксез мәхәббәтләрен белдерделәр. Ә бәлки Владимир Владимировичка үз резиденциясен Төньяк Кавказ республикаларының берәрсенә күчерергәдер? Анда һичьюгы «Путинсыз Россия» митинглары оештырылмый...

Өстәмә тавыш бирү исемлекләре бик еш кына төп исемлекләргә караганда шактый озынрак та иде. Якын төбәкләрдән килүчеләр дә, еракларыннан килүчеләр дә хәттин ашкан булып чыкты. Бер Болотная мәйданында гына да төрле регионнардан килгән 92 автобус бар иде. Самолетлар белән очып килүчеләр дә булды, пароходларда гына йөзеп килә алмадылар, кыш һәм боз комачаулады.

Бу юлы өйдә тавыш бирүчеләр проценты моңа кадәр күрелмәгәнчә югары булды. Тула һәм Тамбов өлкәләрендә сайлаучыларның 20 проценты өйдә тавыш биргән. Һәр бишенче диярлек сайлаучысы инвалид хәлендә икән, губернаторлар Бетин белән Груздев үз регионнарын нинди хәлгә китереп җиткергән булып чыга соң?! Барлыгы 6,5 миллион сайлаучы өйләрендә тавыш биргән.

Әйдәгез, шикле тавышларның барысын да кушып исәпләп карыйк әле. Исемлекләр белән манипуляцияләр ясаудан – 2,5 миллион; «открепительныйлар» белән тавыш бирүдән – 1,6 миллион; вакытыннан алда тавыш бирүчеләр – 240 мең; өйдә сайлаганнар – 6,5 миллион. Нәтиҗә – 11 миллион. Бу Путинны яклап тавыш бирүчеләрнең 25 проценты дигән сүз. Менә ул икенче тур!

Кыскасы, тавыш биреп торасыңмы, тормыйсыңмы, барыбер... сиңа Путин!

Чөнки сайлаулар кандидатлар арасында түгел, ә патриот Зюганов белән черегән, коррупциягә чумган, мафиоз дәүләт машинасы арасында булды.

Тавышны урлап була, беркетмәләрне дә күчереп язарга мөмкин, әмма халык мәхәббәтен урлап булмый! Мондый сайлаулардан соң кешеләрнең: «Патша чын түгел икән бит...» – дип, ешрак кабатлый башлавы да тикмәгә түгел.

# Иске яңа Путинны сайлау

Владимир Путинның матбугат сәркатибе Дмитрий Песков: «Бу темага кире әйләнеп кайтмыйбыз», – дисә дә, кайбер нәтиҗәләр белән уртаклашмый булдыра алмыйм. Кремль тирәсендә кайнашучы төрле сәясәтче, күзәтүчеләр, хәтта Зюганов һәм Прохоровтан кала Путинның бөтен оппонентлары да бу сайлауларны «тарихта булмаганча ачык һәм гадел узды» дип бәяләде. Ә инде оппозициянең күпсанлы хокук, закон бозулар хакындагы дәлилен ишетмәмешкә салыштылар. Имеш, дошман сүзе, АКШ коткысы һәм башкалар…

Хәтта сайлаудан соң интернетта урын алачак закон бозу язмаларына да алдан ук җавап әзерләп куйдылар бит! Сайлауга ике-өч көн кала бюллетеньнәргә тамга салып утыручы сайлау комиссиясе әгъзалары төшерелгән ялган ролик ясап җибәрделәр. Имеш, әле сайлау узмаган, ә дошманнар инде яла ягу белән шөгыльләнә, барысын алдан әзерләп куя, ярый белеп алдык!

Судларны әйтеп тә тормыйм, алар сайлауларга кагылышлы иң ныклы дәлилләрне дә сөенә-сөенә шиклегә чыгара. Кайсы да булса сайлау комиссиясе рәисен хөкемгә тартканнарын да күргәнем юк. Чөнки барысы да гамәлдәге хакимият файдасына эшли. Хакимият исә үзенең тугры әнчекләрен һәрчак яклау ягын таба.

Ярар, узган елның 4 декабрендә РФ Дәүләт Думасына сайлауларның ничек узуын барыбыз да белдек, инде 4 марттагы Президент сайлауларын чистарак узар дигән өмет бар иде. Кремль дә мәйданга чыгучыларның дәгъвасы белән килеште, демократияне арттырырга вәгъдәләр бирде, сайлау участокларына 180 мең видеокамера куелды, бер миллионга якын күзәтүчеләр билгеләнде. Инде моның кадәр чаралар белән дә хәрәмләшеп булмас кебек тоелган иде. Безнең түрәләр аның да җаен тапты. Сайлауларның чисталыгын тәэмин итәргә тиешле видеокамералар Путинның агитация коралына әверелде. Авыл Советы башлыклары авыл кешеләрен шул камералар белән куркытып, Путинга тавыш бирергә өндәп йөрделәр. Имеш, кемгә тавыш биргәнеңне беләчәкбез, кабинага качтым дип уйлама, камера барысын да язып бара. Эшләгән кешеләргә тавышны «кирәкле» Путинга бирмәсә, эшеннән куу белән, карт-корыны кәҗәсенә печән-салам бирмәү, бакчасын сукалатмау белән янап куркытып бетерделәр. Нәтиҗәдә, авыл халкы, бәладән башаяк дип, Путинны сайларга мәҗбүр ителде.

Монысы хокук бозу түгелме? Миңа калса, һәр янау – хокук бозу һәм миңа бу уңайдан күп шалтыратулар булды.

Инде сайлауларга әзерлек мәсьәләсенә килик. Быелгы Президент сайлаулары шактый ук ачык узды. 180 мең камера үзе генә дә ни тора. Алдап кара син аларны! Ләкин безнең түрәләр моның да җаен тапты – сайлау комиссиясе әгъзалары камераларны алдарга, аларның «күрү» мәйданын капларга өйрәтелде.

Электрон адресыбызга Төркиядән бер язма килде. Чит илдәге дусларыбыз Татарстанның Лениногорск районындагы Иске Куак авылында, бюллетень санауны күзәтеп, яздырып барганнар дип аңладым. №1840 дип билгеләнгән бу участокта кызык кына хәл күзәтелә. Сайлау вакыты бетеп, ишекләр бикләнгәч, участокка кап-карадан киенгән бер таза гына ир-ат килеп керә. Бер хатын аны назлап кына биленнән кочып алып өстәл башына китереп бастыра. Йөзе күренми – камерага арты белән тора. Өстәл янына килгәч ул курткасын чишеп җибәрә, шул ук вакытта әрҗәдәге бюллетеньнәрне дә бушаталар. Монда, «кирәкле» кандидат исеме куелган бюллетеньнәр ташланды дип чамаларга була. «Кирәкле» кандидатның кем икәнен чамалыйсыз инде – Прохоров та, Зюганов та түгел дип уйлыйм…

Белмим, бәлки, бу да яла ягудыр? Бәлки, бу видеоязманы Төркиядәге дусларыбыз үзләре әмәлләп җибәргәндер? Ә теге кара киемле таза абзыйның кем икәнен беләсе иде. Хөрмәтле Иске Куак халкы, язып җибәрегез әле, мөмкин булса!

Элекке сайлау күбрәк шәһәрдәге сайлаучыларны алдау, авыл халкын куркыту аша алып барыла иде. Бусында вәзгыять үзгәрде – камераларны алдаргa, ирекле күзәтүчеләрдән котылырга кирәк иде. Монысын оештыру – үзе зур мәшәкать. Биграк тә күзәтүчеләрнең күзен каплау авыр, алар арасында шактый принципиальләре дә булырга мөмкин бит.

Бу уңайдан түрәләребез шактый зирәклек күрсәткән. Алар хәтта сайлау комиссияләре өчен махсус күрсәтмәләр уйлап чыгарган. Анда исә күзәтүчеләрне ничек участоктан чыгарып җибәреп, куып булу юллары күрсәтелгән. Иң гадиләре: ешрак чәй эчәргә чакыру һәм, мөмкинлек чыкса, күбрәк аракы эчертү; әрҗә белән өйдән-өйгә йөреп, сайлатучыны озатып йөртү.

Ә инде кайберләре үтә дә усал һәм кешелексез икән: сайлау участогының иң ерак почмагына урын билгеләү, сайлау урналарына, өстәлләргә якын китермәү, якын килсәләр, бүлмәдән куып чыгару. Шулай ук күзәтүчеләргә сайлаучылар арасыннан бәйләнүчеләр җибәреп гауга чыгару, тәртип бозуга этәрү.

Әгәр күзәтүченең телефон номеры билгеле икән, аңа туктаусыз шалтыратып тору…

Нәтиҗәдә, сайлау участогы ябылыр вакытка күзәтүчеләрнең күпчелеге инде куылган була, кайберләре, мондый басымга түзә алмыйча, үзләре китеп бара. Шулай итеп, РФ Үзәк Сайлау комиссиясенең 180 мең камера һәм миллионга якын күзәтүче катнашында узган сайлаулар хакындагы лаф оруы бары тик чираттагы ялган гына.

Менә шулай кылана торгач, Русия Федерациясе буенча Путин 63,6%, Зюганов 17,18%, Прохоров 7,98% тавыш җыйдылар дип исәпләнә. Гадәттәгечә, Путинга тавышны иң күбен чичән халкы биргән булып чыга. Чичән республикасында ул 99,76% тавыш җыя. Мөгаен, бу республика халкы үзләрен канга батырган өчен рәхмәт әйтәдер. Ә Рамзан Кадыйров исә, быел Мәскәүдән 600 миллиард сум акча сорый – сугыштан соң республиканы төзисе бар.

(Ахыры 4нче биттә)

# Районнар ничек тавыш бирде?

| № | Комиссия | Сайлаучылар саны | Сайлауда катнашу | | Жириновский Владимир Вольфович | | Зюганов Геннадий Андреевич | | Миронов Сергей Михайлович | | Прохоров Михаил Дмитриевич | | Путин Владимир Владимирович | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | 2866307 | 2379562 | 83,02% | 52994 | 2,23% | 229711 | 9,66% | 41878 | 1,76% | 69708 | 2,93% | 1967291 | 82,70% |
| 1 | Әгерже | 25995 | 24553 | 94,45% | 271 | 1,10% | 666 | 2,71% | 233 | 0,95% | 355 | 1,45% | 22985 | 93,61% |
| 2 | Азнакай | 23458 | 20539 | 87,56% | 315 | 1,53% | 2151 | 10,47% | 274 | 1,33% | 377 | 1,84% | 17289 | 84,18% |
| 3 | Азнакай шәһәре | 28226 | 22151 | 78,48% | 318 | 1,44% | 4854 | 21,91% | 450 | 2,03% | 642 | 2,90% | 15565 | 70,27% |
| 4 | Аксубай | 22836 | 22291 | 97,61% | 117 | 0,52% | 337 | 1,51% | 102 | 0,46% | 72 | 0,32% | 21586 | 96,84% |
| 5 | Актаныш | 23221 | 23017 | 99,12% | 122 | 0,53% | 1115 | 4,84% | 136 | 0,59% | 164 | 0,71% | 21422 | 93,07% |
| 6 | Алексеевск | 19905 | 19525 | 98,09% | 180 | 0,92% | 509 | 2,61% | 116 | 0,59% | 131 | 0,67% | 18562 | 95,08% |
| 7 | Әлки | 15193 | 15066 | 99,16% | 35 | 0,23% | 202 | 1,34% | *31 | 0,21% | 26 | 0,17% | 14748 | 97,90% |
| 8 | Әлмәт | 36953 | 34934 | 94,54% | 502 | 1,44% | 1740 | 4,98% | 315 | 0,90% | 320 | 0,92% | 31899 | 91,31% |
| 9 | Әлмәт шәһәре | 109500 | 93417 | 85,31% | 1968 | 2,11% | 11031 | 11,81% | 1457 | 1,56% | 2076 | 2,22% | 75962 | 81,31% |
| 10 | Апас | 15850 | 15781 | 99,56% | 29 | 0,18% | 144 | 0,91% | 17 | 0,11% | 45 | 0,29% | 15513 | 98,30% |
| 11 | Арча | 38756 | 38366 | 98,99% | 151 | 0,39% | 878 | 2,29% | 151 | 0,39% | 155 | 0,40% | 36997 | 96,43% |
| 12 | Әтнә | 10488 | 10458 | 99,71% | 16 | 0,15% | 102 | 0,98% | 17 | 0,16% | 41 | 0,39% | 10238 | 97,90% |
| 13 | Баулы | 10882 | 10366 | 95,26% | 183 | 1,77% | 402 | 3,88% | 86 | 0,83% | 90 | 0,87% | 9562 | 92,25% |
| 14 | Баулы шәһәре | 17505 | 15064 | 86,06% | 448 | 2,97% | 1611 | 10,70% | 437 | 2,90% | 503 | 3,34% | 11957 | 79,38% |
| 15 | Балтач | 25666 | 25047 | 97,59% | 306 | 1,22% | 1100 | 4,39% | 268 | 1,07% | 384 | 1,53% | 22924 | 91,53% |
| 16 | Бөгелмә | 16139 | 15740 | 97,53% | 348 | 2,21% | 1110 | 7,06% | 213 | 1,35% | 225 | 1,43% | 13788 | 87,65% |
| 17 | Бөгелмә шәһәре | 66258 | 58897 | 88,89% | 1980 | 3,36% | 8528 | 14,48% | 1106 | 1,88% | 1075 | 1,83% | 45728 | 77,64% |
| 18 | Буа | 18801 | 18672 | 99,31% | 42 | 0,22% | 399 | 2,14% | 41 | 0,22% | 24 | 0,13% | 18147 | 97,19% |
| 19 | Буа шәһәре | 15807 | 15276 | 96,64% | 54 | 0,35% | 656 | 4,30% | 53 | 0,35% | 30 | 0,20% | 14448 | 94,64% |
| 20 | Югары Ослан | 14058 | 13061 | 92,91% | 411 | 3,15% | 562 | 4,30% | 199 | 1,52% | 303 | 2,32% | 11504 | 88,08% |
| 21 | Биектау | 32889 | 31849 | 96,84% | 138 | 0,43% | 766 | 2,41% | 79 | 0,25% | 142 | 0,45% | 30657 | 96,26% |
| 22 | Чүпрәле | 18882 | 18401 | 97,45% | 128 | 0,70% | 557 | 3,03% | 70 | 0,38% | 113 | 0,61% | 17471 | 94,95% |
| 23 | Алабуга | 8128 | 7958 | 97,91% | 42 | 0,53% | 273 | 3,43% | 30 | 0,38% | 43 | 0,54% | 7552 | 94,99% |
| 24 | Алабуга шәһәре | 52592 | 47484 | 90,29% | 1091 | 2,30% | 5592 | 11,78% | 727 | 1,53% | 737 | 1,55% | 39053 | 82,25% |
| 25 | Зәй | 11608 | 11447 | 98,61% | 28 | 0,24% | 136 | 1,19% | 15 | 0,13% | 18 | 0,16% | 11242 | 98,21% |
| 26 | Зәй шәһәре | 31905 | 30110 | 94,37% | 248 | 0,82% | 1612 | 5,35% | 118 | 0,39% | 260 | 0,86% | 27827 | 92,44% |
| 27 | Зеленодол | 47195 | 43873 | 92,96% | 660 | 1,51% | 2636 | 6,01% | 237 | 0,54% | 456 | 1,04% | 39722 | 90,58% |
| 28 | Зеленодол шәһәре | 77972 | 68439 | 87,77% | 1394 | 2,04% | 7118 | 10,40% | 753 | 1,10% | 1804 | 2,64% | 56920 | 83,18% |
| 29 | Казан, Авиатөзелеш | 91436 | 66158 | 72,35% | 1892 | 2,86% | 8846 | 13,37% | 1521 | 2,30% | 2578 | 3,90% | 50758 | 76,74% |
| 30 | Казан, Вахитов | 67566 | 44965 | 66,55% | 1851 | 4,12% | 4881 | 10,86% | 1718 | 3,82% | 2543 | 5,66% | 33436 | 74,40% |
| 31 | Казан, Киров | 81890 | 56242 | 68,68% | 1924 | 3,43% | 6707 | 11,96% | 1499 | 2,67% | 3378 | 6,02% | 41867 | 74,64% |
| 32 | Казан, Мәскәү | 101177 | 65933 | 65,17% | 3144 | 4,77% | 11577 | 17,57% | 2583 | 3,92% | 7129 | 10,82% | 40452 | 61,38% |
| 33 | Казан, Яңа Савин | 168712 | 118219 | 70,07% | 3211 | 2,72% | 15635 | 13,24% | 2559 | 2,17% | 6244 | 5,29% | 89112 | 75,47% |
| 34 | Казан, Идел буе | 181939 | 119491 | 65,68% | 4440 | 3,72% | 14026 | 11,74% | 4425 | 3,70% | 5105 | 4,27% | 90489 | 75,75% |
| 35 | Казан, Совет | 220330 | 145426 | 66,00% | 5321 | 3,66% | 13035 | 8,97% | 4348 | 2,99% | 9729 | 6,70% | 111424 | 76,69% |
| 36 | Кайбыч | 10609 | 10458 | 98,58% | 90 | 0,86% | 419 | 4,01% | 54 | 0,52% | 109 | 1,04% | 9752 | 93,26% |
| 37 | Кама-Тамагы | 13607 | 13204 | 97,04% | 90 | 0,68% | 650 | 4,92% | 78 | 0,59% | 78 | 0,59% | 12278 | 92,99% |
| 38 | Кукмара | 39603 | 38486 | 97,18% | 195 | 0,51% | 1285 | 3,34% | 135 | 0,35% | 268 | 0,70% | 36552 | 94,97% |
| 39 | Лаеш | 27392 | 26919 | 98,27% | 184 | 0,68% | 480 | 1,78% | 117 | 0,43% | 146 | 0,54% | 25924 | 96,30% |
| 40 | Лениногорск | 17367 | 16671 | 95,99% | 145 | 0,87% | 460 | 2,76% | 110 | 0,66% | 165 | 0,99% | 15771 | 94,61% |
| 41 | Лениногорск шәһәре | 49832 | 41644 | 83,57% | 1103 | 2,65% | 3604 | 8,65% | 611 | 1,47% | 723 | 1,74% | 35358 | 84,91% |
| 42 | Мамадыш | 33361 | 32374 | 97,04% | 320 | 0,99% | 745 | 2,30% | 216 | 0,67% | 222 | 0,69% | 30790 | 95,11% |
| 43 | Менделеев | 21191 | 20400 | 96,27% | 148 | 0,73% | 1252 | 6,14% | 105 | 0,51% | 160 | 0,78% | 18666 | 91,50% |
| 44 | Минзәлә | 21991 | 21634 | 98,38% | 224 | 1,04% | 358 | 1,65% | 122 | 0,56% | 138 | 0,64% | 20781 | 96,06% |
| 45 | Мөслим | 16945 | 16738 | 98,78% | 123 | 0,73% | 217 | 1,30% | 78 | 0,47% | 51 | 0,30% | 16257 | 97,13% |
| 46 | Чаллы, Автозавод | 115663 | 98271 | 84,96% | 2800 | 2,85% | 14844 | 15,11% | 1963 | 1,99% | 3044 | 3,10% | 74456 | 75,77% |
| 47 | Чаллы, Комсомол | 89645 | 76029 | 84,81% | 1824 | 2,40% | 13775 | 18,12% | 1123 | 1,48% | 1822 | 2,40% | 56175 | 73,89% |
| 48 | Чаллы, Үзәк | 138175 | 115857 | 83,85% | 3327 | 2,87% | 19707 | 17,01% | 2538 | 2,19% | 5024 | 4,34% | 84015 | 72,53% |
| 49 | Түбән Кама | 29328 | 25966 | 88,54% | 487 | 1,88% | 2555 | 9,84% | 325 | 1,25% | 384 | 1,48% | 22078 | 85,03% |
| 50 | Түбән Кама шәһәре | 172863 | 135367 | 78,31% | 5734 | 4,24% | 24849 | 18,36% | 5860 | 4,33% | 7358 | 5,44% | 89921 | 66,43% |
| 51 | Яңа Чишмә | 11613 | 11338 | 97,63% | 86 | 0,76% | 133 | 1,17% | 36 | 0,32% | 30 | 0,26% | 11037 | 97,35% |
| 52 | Нурлат | 18364 | 18225 | 99,24% | 37 | 0,20% | 82 | 0,45% | 17 | 0,09% | 10 | 0,05% | 18078 | 99,19% |
| 53 | Нурлат шәһәре | 25890 | 25315 | 97,78% | 39 | 0,15% | 154 | 0,61% | 35 | 0,14% | 55 | 0,22% | 25032 | 98,88% |
| 54 | Питрәч | 21841 | 21243 | 97,26% | 129 | 0,61% | 556 | 2,62% | 113 | 0,53% | 114 | 0,54% | 20307 | 95,61% |
| 55 | Балык Бистәсе | 22167 | 21603 | 97,46% | 209 | 0,97% | 366 | 1,69% | 128 | 0,59% | 147 | 0,68% | 20681 | 95,73% |
| 56 | Саба | 24329 | 23907 | 98,27% | 174 | 0,73% | 534 | 2,23% | 133 | 0,56% | 199 | 0,83% | 22831 | 95,50% |
| 57 | Сарман | 27944 | 27138 | 97,12% | 212 | 0,78% | 542 | 1,99% | 128 | 0,47% | 245 | 0,90% | 25865 | 95,34% |
| 58 | Спас | 15998 | 15695 | 98,11% | 43 | 0,27% | 199 | 1,27% | 187 | 1,19% | 45 | 0,29% | 15199 | 96,84% |
| 59 | Тәтеш | 18952 | 17443 | 92,04% | 169 | 0,97% | 1195 | 6,85% | 119 | 0,68% | 113 | 0,65% | 15753 | 90,32% |
| 60 | Тукай | 26814 | 25296 | 94,34% | 223 | 0,88% | 1677 | 6,63% | 163 | 0,64% | 273 | 1,08% | 22876 | 90,43% |
| 61 | Теләче | 10822 | 10745 | 99,29% | 34 | 0,32% | 61 | 0,57% | 24 | 0,22% | 35 | 0,33% | 10579 | 98,46% |
| 62 | Чирмешән | 12883 | 12855 | 99,78% | 72 | 0,56% | 339 | 2,64% | 51 | 0,40% | 85 | 0,66% | 12286 | 95,58% |
| 63 | Чистай | 14618 | 13607 | 93,08% | 253 | 1,86% | 1049 | 7,71% | 111 | 0,82% | 167 | 1,23% | 11959 | 87,92% |
| 64 | Чистай шәһәре | 49263 | 39706 | 80,60% | 1135 | 2,86% | 5715 | 14,39% | 717 | 1,81% | 1136 | 2,86% | 30699 | 77,32% |
| 65 | Ютазы | 17519 | 17212 | 98,25% | 77 | 0,45% | 415 | 2,41% | 97 | 0,56% | 45 | 0,26% | 16529 | 96,03% |

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

# Иске яңа Путинны сайлау

(Ахыры, башы 3нче биттә)

Ингушетия В.В. Путинга 91,9%, Дагыстан 92,84%, Карачай-Черкес Республикасы 91,36% тавыш бирә. Ә менә Калининград, Орел, Кострома өлкәләре 52%тан аз гына күбрәк; Мәскәү, гомумән 46,95% кына тавыш биргән. Димәк, мөселманнарны, урыс булмаган милләтләрне кысучы Путинны күбрәк мөселман «инородецлар» сайлый булып чыга?! Татарстан гына да аңа 82,7% тавыш бирә! Нәрсә өчен? Мөгаен, милли мәгарифебезне бетергән, республикабызны – губерниягә, Президентыбызны главага калдырырга маташканы өчендер…

Мәскәү Дәүләт Университеты тулай торагында яшәүчеләр биргән тавышларны санасаң, илнең киләчәге булган яшь буын Путинга бөтенләй ышанмый. Анда бу кандидатка 20% кына тавыш бирәләр. Ә менә Прохоров 40% җыя ала.

Хәер, Путин Русия буенча да 63,6% тавыш җыя алмады. Аның чын сайлаучылары чама белән 30% тирәсе генә исәпләнә. Калганының каян килгәнен чамалыйбыз инде. Зюганов дөрес әшләде – ялган тавышлар белән сайланган ялган Президент белән очрашуга бармады, җиңүе белән котламады, аны яңа Президент итеп танымады.

Шулай итеп, иске яңа Президентлы булдык, бу сайлаулар өметне акламады – демократия булмады, тагын да пычраграк технологияләр кулланылды. Ил шул ук – баткаклык, Президент кына башка. Татарның исә бер сүзе бар: ыштан алыштырганнан «арт шәриф» үзгәрми. Дөрес бит, җәмәгать!

**Искәндәр СИРАҖИ.**
(«Безнең гәҗит», №10, 14 март 2012 ел).

**Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе председателе Анатолий ФОМИН:**

## *«Административ ресурс булды, бар һәм булачак»*

Миңа студентлар еш кына, уку йортыннан куып чыгару, янсә укуында проблемалар китереп чыгару белән янап, үзләрен политик тормышка тартырга маташулары, ә аларның моны теләмәүләре турында сораулар бирәләр. Ә мин аларга үзем шундый сорау бирәм: кемне куып чыгарганнар соң әле? Юк бит андыйлар. Әйе, ачыктан-ачык сөйләшәсе, аңлашасы, инандырасы урында, аргументлары, шәхси абруйлары булмаганлыктан, кешеләр белән күтәренке тонда «кирәк» термины кулланып кына эш итүче хәсрәт җитәкчеләр бар инде алар. Билгеле, андыйларга каршы көрәшергә кирәк, җәмгыять шулай корылган бит.

**5 майда «ПРАВДА»газетасына – 100 ел**

**Барлык почта бүлекләрендә дә «ПРАВДА» газетасына язылырга мөмкин.**

**Газетаның индексы: 50102.**

**Ярты елга язылу бәясе: 634,44 сум.**




**Веб-камера протоколларны алдап тутыруны күрмәсә дә, калганын күрә: әлеге 561нче участокта Мәскәүдән килгән КПРФ күзәтүчесен путинчылар төреп алган.**

«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор – Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ
Техник редактор – Наталья КОШКИНА
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
www.kprf.ru («Коммунисты и российское общество»)

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420021, Казан шәһәре, Сул Болак урамы, 56.
Тел./факс: (843) 292-53-26, 292-27-22.
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: график буенча – 16.03.2012 ел, 16.00, кул куелды – 16.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре,
Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 302. Тираж 20000.
Бәясе ирекле.